ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.10.2024 ел Баулы шәһәре №136

2025 елда Баулы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге №273-ФЗ Федераль законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 июлендәге 588 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы, күрсәтелгән мәгариф оешмаларында шундый укучылар санының 100 процентын колачлауны тәэмин итүче укучыларның Татарстан Республикасында түләүсез кайнар туклануны оештыру чаралары исемлеген раслау турында" карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны кайнар туклануның уртача хакын раслау турында», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 16 сентябрендәге 789 номерлы «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү хакы нормативын раслау турында» карарлары нигезендә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тулысынча туклану белән тәэмин итү, гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны сәламәт туклануны оештыру өлешендә туклануны оештыруга карата СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләрен үтәү максатларында, шулай ук укучыларның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУсен Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының Баулы муниципаль районы бюджетыннан ташламалы шартларда район һәм шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында

кайнар ризыкны оештыручы предприятиеләргә субвенцияләр бирү буенча вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

2. 2025 елның 1 гыйнварыннан Баулы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмасында уку чорында бер укучыга көнгә кайнар туклану бәясе күләмен билгеләргә:

Бюджет хисабына:

- шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучылары өчен - 69 сум 43 тиен;

- 5-11 сыйныфта укучылар өчен– 9 сум 60 тиен;

ата-ана кертемнәре исәбеннән:

- 5-11 сыйныфлар өчен:

шәһәрдә: иртәнге аш – 16 сум 38 тиен, төшке аш – 53 сум 07 тиен, озайтылган көн төркеме – 21 сум 84 тиен;

авылда: иртәнге аш – 16 сум 38 тиен, төшке аш– 41 сум 28 тиен.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Д.З. Ганиевага «Социаль өлкәдә ярдәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» (алга таба - БЦП) дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итү турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм БЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров